МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ 220/о

ПРИКАЗ — БОЕРЫК

«13» 12 2016

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 29 февралендәге «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен кабул итеп алу тәртибе турында нигезләмә раслау хакында» № 39/о боерыгына үзгәрешләр кертү турында

**Б о е р ы к   б и р ә м:**

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 29 февралендәге «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен кабул итеп алу тәртибе турында нигезләмә раслау хакында» № 39/о боерыгына (алга таба – боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Боерык белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен кабул итеп алу тәртибе турында нигезләмәнең (алга таба – Нигезләмә) 3-5, 8-11 пунктларында, Нигезләмәнең 1, 3 кушымталарында «кадрлар сәясәте бүлеге» сүзләрен «дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге» сүзләренә алмаштырырга.

2. Юридик бүлек башлыгы Э.Ю.Латыйповага дәүләт теркәвенә алу өчен әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторы җитәкчесе Г.С.Миңнехановага әлеге боерыкның “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

**Министр** **И.Ә.Фәйзуллин**

ОТДЕЛ ОРГАНИЗАЦИОННО-ПРОТОКОЛЬНОЙ РАБОТЫ, КОНТРОЛЯ И ДЕЛОПРОИЗВОДСТВА